ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423190, с. Новошешминск, ул. Ленина, 37 «А»
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ

423190,Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 37 "А"
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

2024 елның «06» сентября № 518

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 96 номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнец административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елныц 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясенец Җир кодексы, Россия Федерациясенец Торак кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенец Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боера:

1. 2.8.2.1 пунктындагы 8 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:
«8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат тарафыннан шартнамә

тозелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, биналар, төзелеш объектлары, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;»

2. Әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Милек һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы рәисе Н. В. Попкова